| СОВЕТ БОЛЬШЕПОЛЯНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЗУР ПОЛЯНКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**19.04.2021** **№ 14**

Зур Полянка ав.

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Зур Полянка авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында**

Казан районара табигать саклау прокуратурасының 2021 елның 17 февралендәге 02-06-2021/5 номерлы протестын карап һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 45 маддәсе, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Полянка авыл җирлеге Уставы нигезендә, гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында

**Зур Полянка авыл җирлеге Советы карар итте:**

1. Зур Полянка авыл җирлеге Советының 2019 елның 22 мартындагы 97 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Зур Полянка авыл җирлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 2 бүлектә түбәндәге сүзләрне төшереп калдырырга:

«рөхсәтсез чүплек - үз белдеге белән (рөхсәтсез) каты көнкүреш, эре габаритлы, төзелеш калдыкларын, юридик яисә физик затлар эшчәнлеге барышында барлыкка килгән башка чүп-чарны, 50 кв. метрдан артык мәйданда һәм 30 куб метрдан артык мәйданда ташлау (урнаштыру) яисә туплау;»;

- 2 бүлекне түбәндәге эчтәлекле яңа абзац белән тулыландырырга:

«каты коммуналь калдыклар - физик затларның куллану процессында торак урыннарында барлыкка килә торган калдыклар, шулай ук үзләренең куллану үзлекләрен шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗларын канәгатьләндерү максатларында торак урыннарында физик затлар тарафыннан алардан файдалану процессында югалткан товарлар. Каты коммуналь калдыкларга шулай ук физик затлар, индивидуаль эшкуарлар эшчәнлеге процессында барлыкка килә торган һәм физик затлар куллану

процессында торак урыннарында барлыкка килә торган калдыкларның составы буенча охшаш калдыклар керә;»;

- Кагыйдәләр тексты буенча «каты көнкүреш калдыклары» сүзләрен тиешле килештә «каты коммуналь калдыклар» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарны Казан районара табигатьне саклау прокуратурасына җибәрергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Зур Полянка авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе** **М.Р.Афанасьева**